РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» июль 2022г. г. Альметьевск № 155

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 13 маендагы 374 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне һәм муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору (азат итү) шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар реестры турында» 2021 елның 30 июлендәге 1290 номерлы карары үз көченә керү сәбәпле

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 13 маендагы 374 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне һәм муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору (азат итү) шартлары турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 28 августындагы 397 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 38 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның, 2 нче кушымтаның 1 пунктларында «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы б пунктчасында, 2 нче кушымтаның 1 пунктындагы б пунктчасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 июнендәге 906 номерлы карары белән "Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар реестры турында" һәм (яисә) коммерциячел булмаган оешмалар реестрына, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәлнең начараюы шартларында зыян күрүчеләрнең артуы, «Коммерциягә карамаган оешмалар

реестры турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июнендәге 847 номерлы карары нигезендә, яңа коронавирус инфекциясен тарату нәтиҗәсендә хәлнең начараюы шартларында зыян күрүчеләрнең артуы” сүзләрен, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестры турында» 2021 елның 30 июлендәге 1290 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советеның икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Минһаҗев И.М.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов